«12» ноября 2022 года №2

КАРАР

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы торак пункты территориясендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, «Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге Яр буе Морквашы авылы территориясе өлешендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2023 елда 6 000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме,- Яр буе Морквашы авылы Заречная урамында җирле әһәмияттәге юлларны ремонтлау, дигән мәсьәлә буенча 2022 елның 12 ноябрендә үткән гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 10 катнашучы, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 6 кеше кертелде.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен 6 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде; "Юк" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1 Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге Яр буе Морквашы торак пункты территориясендә гражданнар җыены булып узган дип, нәтиҗәләр - дөрес дип танырга.

2 «Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге Яр буе Морквашы авылы территориясе өлешендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2023 елда 6 000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Яр буе Морквашы авылы Заречная урамында җирле әһәмияттәге юлларны ремонтлау,

«ӘЙЕ» «ЮК»

дигән мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3 Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге Яр буе Морквашы торак пункты территориясендә гражданнар җыены нәтиҗәләрен Яр буе Морквашы авыл җирлеге мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4 Әлеге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: И. Х. Гаязов